ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур.,1А

СОВЕТ АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Айбаш, ул.Центральная, 1А

Тел./факс: +7(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**21 ноябрь 2023 ел** **№ 73**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 13 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.10.2015 ел, № 13 карарына (советның 26.04.2018 ел, № 113, 17.08.2018 ел, № 125, 28.11.2018 ел, № 140, 30.11.2022 ел, № 51, 12.09.2023 № 68 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"3.2 Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге территориясендә милеккә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Айбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин